ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВОЙКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
ВОЙКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.07.2019 г № 23

**Торак биналарны гражданнар милкенә тапшырганда документлар рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

Гамәлдәге законнарга, шул исәптән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләренә, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр алганда гражданнарның өстәмә гарантияләрен билгеләү өлешендә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 19 июлендәге 204-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләренә туры китерү максатларында

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Войкино авыл җирлеге Башкарма комитетының 2014 елның 18 февралендәге 6 номерлы карары белән расланган гражданнар милкенә торак биналарны тапшырганда документлар рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге эчтәлекле үзгәрешләр кертергә:

- «Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасындагы 2.14 юлларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гариза кәгазьдә Башкарма комитетка тапшырыла. Муниципаль хезмәтлә күрсәтелә торган бинага керү инвалидлар өчен, Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә, җайлаштырылган. Әлеге урын гаризаны рәсмиләштерү өчен өстәл һәм урындыклар, гаризаны тутыру үрнәкләре, хезмәтләрне алу өчен кирәкле булган документлар исемлеген үз эченә алган мәгълүмати стендлар белән җиһазландырылган»;

- 5.1. пунктының 3 пунктчасындагы «тәкъдим итү каралмаган документлар» сүзләрен «тәкъдим итү яки гамәлгә ашыру каралмаган документларны яки мәгълүматны яисә эшләрне башкару» сүзләренә алмаштырырга;
- 5.1. пунктына түбәндәге эчтәлекле 8, 9 һәм 10 пунктчалар өстәргә:

«8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозу;

9) федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган булса, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору;

10) муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тартканда, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, күрсәтелгән документларның яисә мәгълүматның булмавы һәм (яисә) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп итү».

- 5.2. пунктын түбәндәге редакциядәәян итәргә:

5.2. Шикаять кәгазьдә язма формада һәм электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтүче органга бирелә. Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата булган шикаятьләр югары органга (булган очракта) бирелә, андый орган булмаганда шикаятьләр турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесе тарафыннан карала.

Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, аның вазифаи затының, хезмәткәренең, җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата булган шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрен, Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтын (http://www.alekseevskiy.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләренең бердәм порталын (http://uslugi.tatar.ru/), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын (http://www.gosuslugi.ru/) кулланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхси кабул итүе вакытында да кабул ителергә мөмкин.

- 5.7. пунктына түбәндәге эчтәлектәге абзацлар өстәргә:

«Шикаять канәгатьләндерелергә тиешле дип табылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәткәндә, ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм муниципаль хезмәт алу өчен мөрәҗәгать итүчегә алга башкарылырга тиешлегамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаять тиешле дәрәҗәдә канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә бирелгән җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга карата шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә»;

5.8. пунктындагы « тәкъдим итү каралмаган документлар» сүзләрен «тәкъдим итү яки гамәлгә ашыру каралмаган документларны яки мәгълүматны яисә эшләрне башкару» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Войкино авыл җирлеге Башкарма комитетының 18.02.2014 елның 18 февралендәге 18 номерлы карары «торак биналарны гражданнар милкенә тапшырганда документлар рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты» үз көчен югалткан дип таныйрга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында», Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталындагы җирлек сайтында

урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Войкино авыл җирлеге Советы бинасындагы махсус мәгълүмат стенды аша халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан көннән соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Татарстан Республикасы Алексеевск**
**муниципаль районы Войкино авыл җирлегенең**
**башкарма комитеты җитәкчесе Н.П. Шабутдинова**